РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АКСУНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

РЕШЕНИЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКСУ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

КАРАР

26 июнь 2023 ел

№ 74-1

ТР Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, 2013 елның 26 июнендәге 5—ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 26 февралендәге номерлы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советы 66-1 карары (13.02.2020 № 83-1, 20.10.2020 № 4-1, 23.11.2020 № 6-1, 22.12.2020 № 8-1, 23.06.2021 № 24-4, 23.06.2021 № 24-4, 16.07.2021 № 25-1, 02.02.2023 № 66-2, 07.04.2023 № 69-2 карарлары редакциясендә) белән расланган ТР Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (текст буенча алга таба–Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертегез:

1.1. 24.3 пункты.:

1 нче пунктчаны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советның «ТР Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 8 июнендәге 72-1 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Аксу авыл җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов